СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЫЖМАРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
«31» октября 2022г.

**КАРАР**
№ 51

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым җыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы № 131-ФЗ Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге территориясендә үзара салым җыю һәм гражданнарның үзара салымы тәртибе турындагы Пыжмара авыл җирлеге Советының 11.04.2014 елгы № 100нчы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Җирле референдумда кабул ителгән карарларның 1 нче группа инвалидларыннан; үз-үзләренә хезмәт күрсәтә алмаган гражданнардан; балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче ялгыз ата-аналардан (законлы вәкилләрдән); Россия Армиясе сафларында сроклы һәм контракт хезмәтен үтүче, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларына кала (алар өчен үзара салым суммасының 90% күләмендә ташлама билгеләнгән) 18 яшькә җиткән барлык гражданнардан, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтләргә карамастан, үзара салым акчаларын түләү җирлек башкарма комитетының банк реквизитларын, шулай ук түләү тәртибе турындагы мәгълүматны үз эченә алган хәбәрнамә нигезендә өч ай дәвамында башкарыла.

2.Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны районның baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы — Р.Х.Җәләев